РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.05.2015 № 681-п

2015 елның икенче кварталында гражданнар
кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт
хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм «Татарстан Республикасы ипотека торак кредиты агентлыгы» ААЖ мәгълүматы нигезендә ипотека кредиты ставкалары турында

КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елның икенче кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме :

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 088 439 сум
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 385 286 сум
1.1.3. Аларның гаиләсе өчен - 1 781 082 сум
1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2 374 776 сум
1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 2 968 470 сум
1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 3 562 164 сум
1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 155 858 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 14188,21 сум;
1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 9028,86 сум;
1.2.3. Өч кешелек һәм аннан да күбрәк кеше өчен - 7739,02 сум.

2. Саба муниципаль районының авыл (шәһәр) җирлекләре җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә куйганда файдалануны тәкъдим итәргә.

Р.М. Гасимов

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2015 елның II кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү МЕТОДИКАСЫ**

1. **Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече**
   **СЖ= НП х РС х РЦ, монда:**

СЖ-базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;
НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС-гаилә әгъзалары саны;
РЦ - Татарстан Республикасы буенча 1 кв.м. мәйданның уртача исәп-хисап бәясе, ул Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы белән раслана (2015 елның II кварталына - 32 983 сум);
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 32 983 х 33 = 1 088 439 сум
б) ике кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 42 = 1 385 286 сум
в) өч кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 18 х 3 = 1 781 082 сум
г) дүрт кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 18 х 4 = 2 374 776 сум
д) биш кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 18 х 5 = 2 968 470 сум
е) алты кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 18 х 6 = 3 562 164 сум
ж) җиде кешелек гаиләгә:
СЖ = 32 983 х 18 х 7 = 4 155 858 сум

**2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең икеле әһәмияте**

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС/ (1-[1 + ПС) - КП]/ (0,3 х РС), анда**

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;
ПС - кредит буенча процент ставкасы (еллык 12 %) «Татарстан Республикасы ипотека торак кредиты агентлыгы» ААҖ мәгълүматы буенча яисә аена 12/12 %);
КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (кредит бирү срогы 15 ел яисә 180 ай, «Татарстан Республикасы ипотека агентлыгы» ААҖ мәгълүматы нигезендә);
РС-гаилә әгъзалары саны;
0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;
0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
ПД = (0,7 х 1 088 439 х 12/12) / {1-[(1 + 12/12) - 180], [0,3 х 1) = 14188,21 сум
б) ике кешелек гаиләгә:
ПД = (0,7 х 1 385 286 х 12/12) / {1-[(1 + 12/12) - 180] / (0,3 х 2) = 9028,86 сум
в) өч кешелек һәм аннан да күбрәк гаиләгә:
ПД = (0,7 х 1 781 082 х 12/12) / {1-[(1 + 12/12) -180] / (0,3 х) = 7739,02 сум